ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 гыйнвар 2025 ел № 12

Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3943 номерлы Карары белән расланган муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 4 августындагы 3943 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2022 елның 26 декабрендәге 7484 номерлы, 2023 елның 2 июнендәге 4675 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 10 гыйнварындагы
12 номерлы карарына
кушымта

«Муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Форма

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетына

_______________________________________________

_______________________________________________

Муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә арендага яисә
түләүсез файдалануга бирү турында
ГАРИЗА

_________________________________________________________________ адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы __________ кв.м булган ________________________________________ муниципаль мөлкәтне ________________срокка, сатулар үткәрмичә арендага, түләүсез файдалануга

*(кирәклесен сызарга)*

____________________________________________________________________________ нигезендә

(эшчәнлекне гамәлгә ашыруга рөхсәт документы)

_____________________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________________

(мөлкәттән файдалану максаты күрсәтелә)

файдалану өчен бирүне сорыйм.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына карыймы __________________________ (әйе, юк)

Аерым шартлар ______________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) ___________________________________________________________________________;

2) ___________________________________________________________________________;

3) ___________________________________________________________________________.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирүне сорыйм:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетына;

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә;

☐ Башкарма комитетта.

_______________ ___________________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)»

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева